**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 6-40 номерлы карары**

**Казан халык депутатлары Советының**
**2005 елның 30 мартындагы 2-23 номерлы**
**«Казан Мэрының вазифаи билгесе» турындагы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Казан шәһәре Думасы Регламенты нигезендә, муниципаль хокукый актларны камилләштерү һәм Казан шәһәре символикасын куллану мәсьәләләрен җайга салу максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан халык депутатлары Советының 2005 елның 30 мартындагы 2-23 номерлы «Казан Мэрының вазифаи билгесе» турындагы карарының кушымтасына (Казан шәһәре Думасының 2025 елның 26 мартындагы 6-37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктта «Казан шәһәре Думасының яшь буенча иң өлкән депутаты» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**